**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **23.11.2020ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә тезелде:

« Сез 2021 елда Меслим авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Беек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кендезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Такташ урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Мөслим авылында урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм карап тоту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)
- Мөслим авылы зиратына контейнерлар алу; контейнер мәйданчыклары урнаштыру ( коймалау өчен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау);
- карны механикалаштырылган рәвештә чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү;
- Мөслим авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау ( артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу, материал, җиһазлар сатып алу, езеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр башкару, эчәргә яраклы суга анализ үткәрү)
- бәйрәм чараларын үткәрү ("Җиңү кене", "Сабантуй", "Яңа ел " бүләк һәм сувенирлар сатып алу)")
- Мөслим авылында Такташ урамында кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 139 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 101 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 101 кеше «Әйе» позициясе ечен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче Мөслим авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез 2021 елда Меслим авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем

инвалидларыннан, Беек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 теркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Такташ урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Мөслим авылында урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм карап тоту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

- Мөслим авылы зиратына контейнерлар алу; контейнер мәйданчыклары урнаштыру ( коймалау ечен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау);

- карны механикалаштырылган рәвештә чистарту буенча хезмәтләр ечен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре ечен түләү;

- Меслим авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау ( артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу, материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр башкару, эчәргә яраклы суга анализ үткәрү)

- бәйрәм чараларын үткәрү ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Яңа ел " бүләк һәм сувенирлар сатып алу)")

- Меслим авылында Такташ урамында кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 65 йорт.

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге Башлыгы — З.Х.Рахимьянова

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002416
КПП 164301001